УДК 811.512.145'271

***Н.В. Максимов***

# СӨЙЛӘМ: АБСТРАКТ ҺӘМ КОНКРЕТ ТӨШЕНЧӘЛӘР

В статье рассматривается технология обучения татарскому языку как неродному. Обосновывается целесообразность обучения на синтаксической основе.

Выделение синтагматической модели речи в качестве основы обучения неродной речи позволяет акцентировать внимание обучаемого на алгоритме построения словосочетаний и предложений. Опора на алгоритмы помогает обучаемому варьировать стабильными синтаксическими конструкциями в процессе создания текста-основы и выстраивания диалога.

**Ключевые слова:** татарский язык, технология обучения языку как неродному, синтагматическая модель речи, алгоритм построения словосочетаний и предложений, синтаксические конструкции.

Жирдә яшәүче һәр халыкның мең еллар дәвамында буыннар аша аңына табигый рәвештә салынган, сеңдерелгән үзенчәлекле яңгырашлы һәм язылышлы, тирә-яктагы әйберләргә, гамәлләргә, күренешләргә һ.б.га үзенчә мәгънә салып аталган үз сүзләреннән, үзенә генә хас аһәңле әйтелешле, үзара ярашлы һәм үзенә генә хас эзлеклелектәге фикерләү рәвешенә корылган үз җөмлә калыпларыннан төзелгән *нигез теле – ана теле – сөйләмә теле* бар. Бу – беренчедән. Икенчедән, дөньядагы күпчелек телләрнең гасырлар дәвамында махсус фән белгечләре тарафыннан өйрәнелгән һәм төзелгән, кайтып-кайтып тулыландырылган һәм камилләштерелгән, рәсми кабул ителгән фәнни грамматикалары һәм аларда тупланган кагыйдәләр нигезендә барлыкка килгән *әдәби сөйләм теле* бар.

Математика терминнарын кулланып аңлатсак, ***гади сөйләм теле*** – бала өчен – *арифметика* дәрәҗәсе (*кушу, алу, тапкырлау, бүлү* гамәлләре); ***әдәби сөйләм теле*** – *алгебра* (*кушу, алу, тапкырлау, бүлү гамәлләрендә кулланылган саннарның зурлыкларын хәрефләр һәм саннар ярдәмендә бирелгән күләмдә аңлата белү*) һәм *геометрия* (*пространстводагы җисемнәрнең формасын, күләмен һ.б. формулаларда нигезләп таба һәм исбатлый белү*) дәрәҗәсе.

Илдә яки дөньяда яшәгән халыкның күпчелеге өйдә яки көндәлек тормышта, нигездә, *кушу* һәм *алу, тапкырлау* һәм *бүлү* гамәлләрен генә кулланып эш итә. Бик аз өлеше генә – махсус тармак белгечләре генә – көндәлек тормышта яки эш урынында алгебра һәм геометрия өлкәсенә караган терминнарны һәм гамәлләрне кулланып аралаша.

Сөйләмдә дә шулай: халыкның сөйләү һәм аралашу теле сорау һәм җавап сүзләргә нигезләнеп формалаша. Сөйләгәндә һәм сөйләшкәндә (аралашканда) бирәү дә, шул исәптән тел белгечләре үзләре дә, сөйләменең логик-грамматик (структур-семантик) төзелеше турында уйламый – сорау сүзенең

эчтәлегенә һәм формасына яраклаштырып, җавап сүзен әйтә. Бу очракта җавап сүз урынында, нигездә, кайсыдыр сүз төркеменә караган мөстәкыйль мәгънәле бер генә сүз дә, гади җөмләнең баш яки иярчен кисәге дә; иярчен җөмләле кушма җөмләләрнең баш җөмләсе дә, иярчен аналитик һәм синтетик формалары да; катлаулы төзелмәләрнең баш һәм иярчен җөмлә булган компонентлары да кулланылырга мөмкин.

Бала, мәктәптә укый башлаганчы, тел белеме фәненә кагылышы булган бер генә кагыйдәне белмәсә дә, өйдә әнисенә һәм әтисенә, әбисенә һәм бабасына – олыларга ияреп, белгән кадәрле сүз байлыгыннан һәм хәтерендә калган сорау һәм җавап белдерүче җөмлә калыпларыннан файдаланып, күргәне яки кемнәндер ишеткәннәре турында сөйләргә (*монолог-хикәя* төзергә) һәм шулар хакында, үз фикерен белдереп яки яклап, аралашырга (*диалогта* катнашырга) өйрәнә. Бу – баланың «Тел белеме» дигән фәннең иң гади сүзләр һәм җөмләләр белән бәйле үзенчәлекле төп гамәлләрен белү дәрәҗәсе.

Мәктәптә башлангыч сыйныфларда укый башлагач исә, балага «Тел белеме» дигән фәннең катлаулырак гамәлләрен, «Методика» дигән фән белән шөгыльләнүче галимнәр аңлатканча, сыйныфтан сыйныфка «гадидән катлаулырак эзлеклелектә» махсус әзерләнгән тел белгече – укытучы өйрәтә башлый. Нәтиҗәдә бала, акрынлап, өендә олылар белән аралашып, 4–5 ел дәвамында сорау һәм җавап сүзләр, сорау һәм җавап җөмләләр ярдәмендә сөйләшеп күнегелгән табигый сөйләм теленнән ераклаштырылып, фәнни терминнар һәм кагыйдәләргә нигезләнеп төзелгән логик-грамматик төшенчәләрне, аларның үзлекләрен өйрәнү теленә – үзе өчен ясалма сөйләшү телен өйрәнүгә күчерелә.

Шулай итеп, бала аңы өчен берсе икенчесе белән бөтенләй бәйләнеше булмаган ике төркем гомумиләштерү барлыкка килә: беренче төркемдә реаль чынбарлыкта булган предметлар; аларның төренә, эшенә төрле билгеләренә карап, халык тарафыннан мең еллар элек бирелгән атамалары (предмет = сүз, гамәл = сүз, сан = сүз, билге = сүз һ.б.) һәм шул предметларга, атамаларга карата гомумиләштереп кулланылган, сөйләмдә эчтәлекне бирү өчен кирәкле конкрет мәгънә белдерүче ***сорау*** һәм ***җавап сүзләр***; икенче төркемдә исә бала аңы өчен чынбарлык белән бәйләнеше бөтенләй булмаган, ләкин сөйләмнең логик-грамматик (структур-семантик) төзелеше өчен бик кирәк булган абстракт төшенчәләр: мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүз төркемнәре, модаль сүз төркемнәре; сүзтезмәләр, җөмләләр, җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре; тезмә кушма җөмләләр, синтетик һәм аналитик иярчен җөмләле кушма җөмләләр; катлаулы төзелмәләр; тыныш билгеләре, теркәгечләр, бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр; төрле сызыклардан, парлы җәяләрдән, турыпочмаклыклардан һәм тыныш билгеләреннән торган схемалар туплана. Таблицада аларның бер өлешен, гомумиләштереп, түбәндәгечә күрсәтеп булыр иде:

| Сүз | | Логик-грамматик | |
|---|---|---|---|
| *сорау* | *җавап* | *морфологик* | *синтаксик* |
| **сүзләр** | | **кисәкләр** | |
| кем | мин, син, ул | *мөст. сүз төрк.* | *гади җөмлә* |
| | без, сез, алар | исем | |
| | кеше, бала | сыйфат | *баш кисәкләр* |
| нәрсә | күбәләк, куян | сан | ия, хәбәр |
| | алма, кишер | рәвеш | *тыныш билгеләре* |
| | китап, дәфтәр | алмашлык | |
| кайсы | бу, теге, ул | фигыль | *иярчен кисәкләр* |
| нинди | матур, кызыл | аваз ияртемнәре | аергыч |
| ничә | бер, унбер | | тәмамлык |
| ничек | тиз, салмак | *ярдәмлек сүз төрк.* | хәлләр |
| | утырып, көлеп | бәйлек, бәйлек сүз. | аныклагыч |
| | җәяү | теркәгечләр | |
| кайчан | бүген, иртәгә | | *кушма җөмлә* |
| | җәен, кышын | *модаль сүз төрк.* | тезмә кушма җөмлә |
| кая | авылга, шәһәргә | кисәкчәләр | синтетик, аналитик |
| | мәктәпкә, паркка | кереш сүзләр | иярчен җөмлә |
| нәрсәдә | машинада | эндәш сүзләр | катлаулы төзелмә |
| нишлә | чык, бар, кер | ымлыклар | текст |

Кеше, бала вакытта тәпи киткәч тә, гомере буе йөри: туган яки торган җиреннән башлап хәрәкәт итә, ягъни кая да булса **бара** – кайдан да булса **кайта**, **килә – китә**, **чыга – керә**, **менә – төшә**. Җөмлә кисәкләренең логик-грамматик бүленеше ягыннан караганда, без бу сүзләрне җөмләдә, **хәбәр** буларак, гадәттә түбәндәгечә билгелибез: 1) җөмләдә ия турында хәбәр итә һәм аңа грамматик буйсына торган кисәк; 2) фигыль хәбәр; 3) гади фигыль хәбәр. Ләкин хәрәкәтне белдерүче бу сүзләрнең җөмләдә хәбәр булуы да; хәбәр буларак, санап үтелгән билгеләренең дә татар телендә сөйләүче һәм үзара сөйләшүче кешеләр өчен әллә ни әһәмияте юк, тагын да ачыграк итеп әйтсәк, сөйләүче һәм аралашучы кеше өчен бу мәгълүматларны белү кирәк тә түгел.

Кемне дә булса (баланымы, мәктәп укучысынмы, олы кешенеме – яшь үзенчәлекләренә карамастан) татар телендә сөйләшергә өйрәтүчегә һәм татар телендә сөйләшергә үзлегеннән өйрәнүчегә, беренче чиратта: 1) бу сүзләрнең лексик мәгънәсен – *хәрәкәтне* белдерүен; 2) бу сүзләр ярдәмендә сөйләмдә *вакыт* төшенчәсенең – хәрәкәтнең сөйләү яки сөйләшү вакытына туры килүен, сөйләү яки сөйләшү вакытыннан соң үтәлүен, сөйләү яки сөйләшү вакытына кадәр булуы турындагы грамматик мәгънәләрнең белдерелүен; 3) бары тик бу сүзләрдә генә сөйләмдә катнашучы затларның – I һәм II затның – махсус кушымчалар ярдәмендә белдерелүен; бу сүзләр нәкъ менә шул кушымчалар ярдәмендә сөйләүче (мин) һәм тыңлаучы (син) зат белән берлектә һәм күплектә ярашуын белү һәм аңлау кирәк.

| **Кем**? *кто*? | **Нишлим**? *что делаю*? | **Нишлибез**? *что делаем*? | **Нишләде**? *что сделал*? | **Нишләмәде**? *что сделали*? |
|---|---|---|---|---|
| **I**<br>**Мин**<br><br>**Без** | бара**м**<br><br>бара**быз** | бармый**м**<br><br>бармый**быз** | барды**м**<br><br>барды**к** | бармады**м**<br><br>бармады**к** |
| **II**<br>**Син**<br><br><br><br><br><br>**Сез** | бара**сың**?<br><br>бара**сың**мы?<br><br>бар<br><br>бара**сыз**?<br><br>бара**сыз**мы?<br><br>бар**ыгыз** | бармый**сың**?<br><br>бармый**сың**мы?<br><br>барма<br><br>бармый**сыз**?<br><br>бармый**сыз**мы?<br><br>барма**гыз** | барды**ң**?<br>баргансың<br>барды**ң**мы?<br><br><br><br>барды**гыз**?<br>баргансыз<br>барды**гыз**мы? | бармады**ң**?<br>бармагансың<br>бармады**ң**мы?<br><br><br><br>бармады**гыз**?<br>бармаган**сыз**<br>бармады**гыз**-мы? |

Сөйләм конкрет һәм абстракт мәгънә белдерүче лексик материал, башта – җыйнак, соңрак җәенке җөмлә калыплары ярдәмендә генә сөйләм предметы турындагы темага нигезләнеп оеша; һәм, сөйләм оешсын өчен, беренче чиратта, **сөйләүче** – I зат – сөйләмдә конкрет яки абстракт мәгънә белдерүче предмет турында башкаларга яңалык әйтүче, яңа хәбәрне җиткерүче кеше кирәк. Сөйләүче генә сөйләмнең логик-грамматик (структур-семантик) нигезен төзи ала. Бары ул гына чынбарлыктагы җанлы һәм җансыз предметларны күрә, алар турында, аларга хас үзенчәлекле билгеләр турында кемгәдер (тыңлаучыларына) нәрсә дә булса хәбәр итә, яңалык әйтә ала. Башкалар да күрергә мөмкин, ләкин әйтә алмый. Алай гына да түгел, ул гына башка кешеләр әйткән фикергә үз мөнәсәбәтен белдерә ала: тыңлаучыларының – II һәм III затларның – чынбарлыктагы җанлы һәм җансыз предметларны ни рәвештә кабул итеп, күргәннәре турында тагын да башка тыңлаучыларга хәбәр итү, яңалык буларак әйтү рәвешен, эмоциональ халәтен дә ул гына сөйли ала; ул гына, башкаларның фикерен белергә теләсә, аларга сорау бирә ала.

**Сөйләүче** булмаса, 3 этаптан торган һәм бер-берсенә эзлекле бәйләнгән сөйләм буыннары үзара ялгана алмый, ягъни, беренчедән, сөйләмнең темасы билгеләнә алмый; икенчедән, сөйләүченең монолог – хикәясе төзелә алмый; өченчедән, димәк, I һәм II зат; I, II, III затлар арасында кара-каршы сөйләшү булсын өчен – диалог оешсын өчен, нигез (башлангыч) текст төзелә алмый; дүртенчедән, сөйләшүләр булмагач, сөйләшүнең эчтәлеге турында кемнеңдер (мәсәлән, булган хәл турында ишетеп

кенә белүчеләрнең) кемгәдер нәрсәдер сөйләү мөмкинлеге була алмый.

Мисал өчен, өч дус – Марат (I зат), Саша (II зат), Гүзәл (III зат) арасында 3 этапта барган сөйләшүнең эчтәлегенә һәм оештырылу формасына, ягъни сөйләм синтаксисының оешу үзенчәлегенә игътибар итик.

**1 нче этап**

**I затның (сөйләүченең) монолог-хикәясе:**

*Мин барам! Мин* ***кая*** *бараммы?! Мин* ***мәктәпкә*** *барам. Мин мәктәпкә* ***кем белән*** *бараммы?! Мин мәктәпкә* ***әнием белән*** *барам. Мин мәктәпкә* ***кайчан*** *бараммы?! Мин мәктәпкә* ***бүген иртән*** *барам. Әйе, мин мәктәпкә бүген иртән әнием белән барам.*

**2 нче этап**

**I (мин) һәм II зат (син) арасында кара-каршы сөйләшү (диалог):**

*– Марат, мин мәктәпкә барам. Әйт әле, син* ***кая*** *барасың?*

*– Саша, беләсең килсә – әйтәм: мин дә* ***мәктәпкә*** *барам. Мин мәктәпкә әнием белән барам, ә син, дустым, кем белән барасың?*

*– Мин* ***кем белән*** *бараммы?! Марат, беләсең килсә, мин дә* ***әнием белән*** *барам. Иртән барам. Әйт әле, Марат, син мәктәпкә* ***кайчан*** *барасың?*

*– Шулаймыни?! Иртән барасыңмыни?! Мин мәктәпкә* ***төштән соң*** *барам, беләсең килсә!*

**3 нче этап**

**I (мин), II зат (син), III зат (ул) арасында кара-каршы сөйләшү (диалог):**

*– Саша, мин дә мәктәпкә барам, син дә мәктәпкә барасың. Сора әле, Гүзәл мәктәпкә барамы?*

*– Гүзәл, әйт әле, син бүген мәктәпкә барасыңмы?*

*– Саша, беләсең килсә – әйтәм: мин дә мәктәпкә барам.*

*– Марат, Гүзәл дә бүген мәктәпкә бара икән.*

*– Саша, мин дә мәктәпкә әнием белән барам, син дә мәктәпкә әниең белән барасың. Сора әле, Гүзәл бүген мәктәпкә әнисе белән барамы?*

*– Гүзәл, әйт әле, син бүген мәктәпкә кем белән барасың?*

*– Саша, мин бүген мәктәпкә кем белән бараммы?! Дустым, беләсең килсә, мин бүген мәктәпкә әбием белән барам.*

*– Марат, Гүзәл бүген мәктәпкә әбисе белән бара икән.*

*– Саша, сора әле, Гүзәл мәктәпкә төшкә кадәр барамы, әллә төштән соң барамы?*

*– Гүзәл, әйт әле, син мәктәпкә төшкә кадәр барасыңмы, әллә төштән соң барасыңмы?*

*– Саша, мин бүген мәктәпкә төштән соң барам, чөнки төшкә кадәр бассейнга барам.*

*– Марат, Гүзәл бүген мәктәпкә төштән соң бара икән, чөнки төшкә кадәр бассейнга бара.*

*– Димәк, мин мәктәпкә бүген иртән барам; син, Саша, төштән соң барасың; Гүзәл дә төштән соң бара. Мин әнием белән барам, син дә әниең белән барасың, ә Гүзәл әбисе белән бара.*

Сөйләм калыбында III зат, әгәр аңа I зат турыдан-туры мөрәҗәгать итмәсә, сөйләмдә

бөтенләй катнаштырылмый, шул сәбәпле ул I затка – сөйләр, I һәм II затка, үзара сөйләшү өчен, билгеле яки билгеле булмаган кайсыдыр бер яки берничә объект (мәсәлән: I яки II затка караган *кешеләр: әнием, әтиең, апаң* һ.б.; җанлы һәм җансыз предметлар: *урман, табигать, кибет, агач, сандугач, аю, су анасы, шүрәле* һ.б.) ролен генә үти, шуңа күрә сөйләмдә ул зат еш кына үзе дә абстракт мәгънә генә белдерә, конкрет мәгънә белдерсен өчен, үзен аныклауны таләп итә. Бу вазыйфаны да сөйләмдә, нигездә, сөйләүче генә башкара ала.

**Әдәбият**

*Закиев М.З.* Татарская грамматика. Т. 3. Синтаксис. Казан: Таткнигоиздат, 1995. 576 б.

*Максимов Н.В.* Словосочетания как основа обучения неродному языку // Вестник КГТУ, Т. 16. № 7. 2013. С. 325–328.

*Максимов Н.В.* Сөйләм калыбы – гади җөмлә. Казань: Изд-во РИО ГБУ «РЦМКО», 2013. С. 286–294.

*Максимов Н.В.* Сөйләм калыбы өч этапта формалаша // Сохранение и развитие родных языков в условиях многонацио-нального государства: проблемы и перспективы. V Междуна-родная научно-практическая конференция, 19–22 ноября 2014 г. Казань: Отчество, 2014. С. 180–183.

*Максимов Н.В.* Сөйләм калыбы ул – сөйләмгә өйрәтүнең нигезе // Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы. Материалы региональной научно-практической конференции, посвящённой 190 летию со дня рождения Каюма Насыри. Казань, 2015. С. 139–147.

*Максимов Н.В.* Сөйләшергә өйрәтү формуласы. Казан: Мәгариф. Татар теле. 2016. № 1. 42 б.

*Максимов Н.В.* Телгә өйрәтү технологиясе // Фәнни Татарстан. 2014. № 3. С. 106–112.

*Максимов Н.В.* Технология обучения татарскому языку на основе моделей речи. (На русском и татарском языках). Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. 255 с.

*Сафиуллина Ф.С.* Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Хәтер, 2001. 432 б.

***Максимов Николай Валентинович,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар тел белеме кафедрасы доценты*